



*Куәм урта гомуми белем мәктәбе газетасы* *№3 Ноябрь, 2025 ел*

**30 нчы ноябрь – кадерле Әниләребезнең бәйрәме. Бәйрәмегездә Сезгә озын, сәламәт гомер, тыныч тормыш һәм эшегездә зурдан - зур уңышлар телибез. Йөзегездән гел елмаю китмәсен,шатлык кына балкысын.**



**Әнием.**

Әни... Әнием... Нинди ягымлы һәм йөрәккә якын бу исем! “Әни ”дип эндәшә алу – үзе зур бәхет ул. Мин – дөньяда бик бәхетле кеше, чөнки янәшәмдә минем өчен җан атучы, сөенгәндә шатлыгымны уртаклашучы , кочагына сыенганда: ”Кызым, сабыр бул!” –дип иркәләп эндәшүче газиз әнием бар.

Әни! Һәр кеше өчен иң кадерле, иң хөрмәтле, иң якын кеше ул. Авыр чакларыбызда да, шатлыклы минутларыбызда да без әниләребезнең җылы кочагына сыенабыз. Әниләрнең йөрәк җылысы, “Балам!” дип эндәшкән ягымлы сүзләре безгә яшәргә көч бирә. Йомшак куллары белән башыңнан бер сыйпап узса, бөтен авыруларың, борчуларың беткән кебек була. Әнә шундый тылсымлы, бөек көчкә ия ул- ана дигән изге зат.

Әгәр без бүген зәңгәр күктә йөзгән ак болытларга, кояшлы җылы яңгырларга, түбәләрдән тып-тып итеп тамган язгы тамчыларга карап сөенәбез икән, без моның өчен әнкәйләребезгә бурычлы. Чөнки алар - безгә бу матур дөньяны бүләк итүчеләр, төнге йокыларын йокламыйча, җил-яңгыр тидермичә безне үстерүчеләр. Димәк, алар – безне яклаучыбыз да, саклаучыбыз да.

Минем үземнең әнием турында язып үтәсем килә. Һәркемгә үз әнисе дөньядагы иң кадерле кеше булган кебек, миңа да үз әнием – кадерлеләрдән дә иң кадерлесе. Барлык кешенеке кебек, минем дә телем "әни" сүзе белән ачылган. Әниемнең йомшак куллары, ягымлы тавышы гына да миңа шатлык китерә.

Әнием тәмле ризыклары, матур сүзләре, ачык йөзе күңелгә җылы бирә. Әни булганда , өебез нурлы, аның күзләреннән бөркелгән нур һәрберебезгә җылылык бирә. Әнием янәшәсендә булганда гына мин үземне бәхетле хис итәм. Әнием кешеләргә карата шәфкатьле, ягымлы, ярдәмчел булырга өйрәтте, минем миһербанлы, шәфкатьле , акыллы булып үсүемне теләде. Әниемнең биргән киңәшләре җанга дәва бирә, киләчәккә ышаныч уята, яшәү дәрте бирә. Өныгын үстергәндә дә, бөтен җан җылысын биреп үстереште. Хәзер дә улым дип , өзелеп тора. Һәр көн һәм төн улым дип уяна һәм ята.

“Җәннәт - аналарның аяк астында,” -диләр. Әйе, бу дөрестән дә шулай. Һәрбер ана үзенең йөрәк җимеше - баласы өчен кайгырып яши. Үз чиратыбызда , без дә, әниләребезне яратып, аларга кайгы-хәсрәтләр китермичә яшик. Әниләребезнең йөзләреннән беркайчан да елмаю чаткылары сүнмәсен иде. Барыр юлларыбызны яктыртып торучы, мәңге сүрелмәслек кояшыбыз бит алар безнең.

**Сөнгатова Гөлнара Зөлкарь кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы**

**Әниләр көне**



30 нчы ноябрь илебездә “Әниләр көне “ дип билгеләп үтелде . Без, 4 нче сыйныф укучылары, кадерле әниләребезгә видеокотлау җибәрдек . Кадерле әниләребезне котлап җыр башкардык, матур теләкләребезне әйттек. Әниләребезгә озын гомер, сәламәтлек , бәхет теләдек. Хезмәт (технология) дәресендә үз кулларыгыз белән ясаган бүләкләребезне тапшырдык. Әниләргә бүләкләребез ошады,бик яратып кабул иттеләр, рәхмәт әйттеләр.


**4 нче сыйныф укучысы Брча Амира**

**Кадерле әнием**

Безнең гаиләдә әни иң кадерле кеше. Минем әнием Камил кызы Альбина 1993 нче елда Бахтияр авылында туа. Гаиләдә өч кыз үсәләр, әниемнең апасы һәм сеңлесе бар. Әнием мәктәптә тырышып укый, белем ала, аннан һөнәр алырга укый. Гаиләбезнең әни якты кояшы, ул җылыта да, яктырта да, гел көләч һәм ачык күңелле. Әнием матурлыкны ярата. Чәчәкләр һәм гөлләр үстерә. Күңеле дә чиста, матур шигырьләр дә яза. Минем әни мәдәният йортында эшли. Ул барысына да өлгерә. Тәмле ризыклар да пешерә. Бәйрәмнәрдә табын корырга булышабыз. Минем ике энем бар, абый буларак, аларны карап торам, уйнатып алам, китаплар карыйбыз, рәсемнәр ясыйбыз. Мине ул энеләремә үрнәк итеп куя. Мин тәртипле булырга тырышам, өйдә әнигә булышам. Әни үзенең бала чактагы күңелле вакытларны сөйли. Ул безне аңлый, кайгырта, киңәшләр дә бирә.

Әти, әни, мин бергәләп конкурсларга да катнашабыз. Тату сыйныф серләре конкурсында бергәләп зур сәхнәдә чыгыш ясадык. Классны бизәү өчен әти - әни белән камин макетын да эшләдек һәм аны буяп, бизәп тә куйдык. Әнием ул бик ярдәмчел, Дусым авылының өлкән кешеләре аңа бик рәхмәтле. Ул клубта күп чаралар уздыра, авыл халкы белән аралашып яши. Балалар өчен түгәрәкләр дә үткәрә, концертлар оештыралар. Әни тырышып укып, яхшы билгеләр алсам мине мактап куя. Өйдә өй эшләрендә булышабыз.Быел җәй гаилә белән бергә матур сәяхәттә булдык, ял иттек. Әти, әни белән су коендык, кояшта кызындык. Бергә эшләү дә ял итү дә күңелле.

**6 класс укучысы Хәкимов Әсхәт**



**Әниләр көне**

Әнием – син минем бердәнберем!
Мин бит сине бик тә яратам!
Синең күзләреңә карыймын да
Барлык борчуларым таратам!

Җәннәт әниләрнең аяк астында,- дигән борынгылар. Бары тик газиз кеше генә сина бөтен җан җылысын, назын, тәрбиясен бирә ала. Әниләрнең безгә кылган яхшылыкларын без , балалар мәңге түләп бетерә алмыйбыз. Нинди генә үрләр яуласак та, гамәлләр кылсак та әниләр алдындагы бурычны без үтәп бетерә алмабыз.

Быел без 5 нче сыйныф укучылары “Әниләр көне” билгеләп үттек. Бәйрәм бик күңелле һәм тәрбияви үтте. Без әниләргә багышлап шигырьләр, җырлар башкардык. Аннары өстәл артына җыйналып тәмле чәй белән сыйландык. Чәйләп алган арада төрле мавыктыргыч, күңелле һәм интерактив уеннар уйнадык. Сыйныф җитәкчебез Алия Рустамовна безне дә, әнләребезне дә куандыра алды. Безгә бу бәйрәм бик ошады.

**5 нче сыйныф укучысы Низомов Джәмшит**



**Кеше хокукларын өйрәнү буенча бердәм дәрес**

2 нче декабрь көнне без, 7 нче сыйныф укучылары, кеше хокукларын өйрәнү буенча бөтенрәсәй бердәм дәресенә кушылдык. Анда без кеше хокуклары Декларациясе, дәүләтебезнең төп законы – Конституциядә язылган хокукларыбыз, ирекләребез һәм бурычларыбыз турында белдек. Эш дәфтәрендә кеше хокуклары темасына биремнәр эшләдек, видеоролик карадык. Үз хокукларыңны һәм бурычларыңны белү бик мөһим!

**Садриева Айсинә, 7 нче сыйныф укучысы**

**Минем песием.**

Минем песием бар. Аңа 2 ай. Исеме Царапка. Ул шундый матур, йомшак. Песинең башында ак колаклары, зур күзләре, мыеклары бар. Аның гәүдәсе матур, тәпиләре йомшак, ә тырнаклары үткен, койрыгы озын. Ул сөт эчә һәм мияу-мияу,- дип иркәләнә. Мин мәктәптән кайткач Царапкам бик куана. Йөгереп каршыма килә. Песиларне рәнҗетергә ярамый.

**3 класс укучысы Садриева Ралия**




“Минем шәҗәрәм” конкурсы

Мин ”Минем шәҗәрәм” республика - күләм конкурсында катнаштым һәм иҗади эшем жюри тарафыннан югары бәяләнде. Быел конкурс 162 катнашучыны җыйды һәм мин беренче төркемдә 3нче урынны алдым.15 нче ноябрь көнне Казанга “Созвездие-Йолдызлык” театрына барып бүләкләндем.

2018 нче елдан башланган бу конкурс яшьләрне үз гаиләләре тарихын өйрәнергә,ата-бабалар турындагы белемнәрен киләчәк буыннарга тапшыруга һәм Татарстан тарихы белән кызыксынуга юнәлтә.

**2 нче сыйныф укучысы Галимзянова Ясминә**



**Кошларга безнең ярдәм.**

Менә суык кыш та килеп җитте. Кыш көне кошларга яшәү аеруча да кыенлаша, чөнки азык табу җиңелләрдән бирелми.

Кошларга ярдәм итү йөзеннән, без әтием белән икәү җимлек ясадык. Мин аны классташларым белән мәктәп каршындагы агач ботагына элдем. Җимлеккә без төрледән-төрле ярмалар салдык һәм канатлы дусларыбызны көтә башладык. Икенче көнне алар без куйган җимлекне мактап бәйрәм итәләр иде. Бу минутларда без кошларга ярдәм итә алуыбызга чиксез бәхетле идек.

**3 нче сыйныф укучысы Галявиев Ранил**

**Кышны көтәбез**

Менә кышка да аяк бастык. Ләкин урамда кар юк бит. Күңел Яңа елны көтә, тик кар булмагач кәеф бераз төшә. Урамда һаман көз кебек, көн дә яңгыр ява, аяк аслары пычрак. Быел көз бездә озаграк булырга тели ахры.

Ярар, күңелсезләнмик. Иртән торышка матур итеп кар да явып куяр әле. Бу матур күренешне олысы-кечесе дә көтәдер дип уйлыйм.

**3 нче сыйныф укучысы Василов Азат**

## Әни - һөнәре

Кайбер һөнәрләр өчен диплом кирәк, кайберләре өчен махсус белемнәр. Әмма бу дөньяда шундый бер һөнәр бар, ул йөрәк, җан һәм чиксез мәхәббәт белән башкарыла. Бу — Әни булу һөнәре. Бүген без бу һөнәрнең мөһимлеге, катлаулылыгы һәм әһәмияте турында сөйләшәчәкбез. Әни — гади генә сүз түгел, ул — тормышның нигезе, иң зур бәхетебез һәм иң зур таянычыбыз. Һәр бала өчен, һәр гаилә өчен бу һөнәрнең актуальлеге чиксез. Чөнки әни — ул бер үк вакытта укытучы, тәрбияче, табиб, психолог, пешекче, бухгалтер, киңәшче һәм иң мөһиме — яратучы йөрәк. Әмма бу хезмәт өчен хезмәт хакы түләнми, монда иң зур бүләк — балаларның мәхәббәте һәм бәхете.

Минем әниемне тасвирлаганда, беренче чиратта, аның игелеге һәм сабырлыгы искә төшә. Ул һәрвакыт көләч йөзле, аның тавышында һәм күз карашында тынычлык һәм җылылык бар. Әни безнең гаилә учагын саклаучы. Аның янында мин үземне һәрвакыт бәхетле һәм яратылган итеп хис итәм. Әнинең тәмле ризыклары белән тулы өстәл, өйдәге чисталык һәм тәртип — болар барысы да аның тырыш хезмәте нәтиҗәсе. "Әни" һөнәре — ул 24/7 эш режимы. Бу эштә ял, больничный һәм отпуск дигән төшенчәләр юк. Әни һәрвакыт "эштә". Ул безне иртән уянган беренче минуттан алып, йокыга киткән соңгы минутка кадәр кайгыртта.Әни безнең өчен укытучы да , тәрбияче дә .Ул безгә беренче сүзләрне, әхлак кагыйдәләрен, дөньяны танырга өйрәтә. Ул безгә гаделлек, игелек һәм кешелеклелек орлыкларын сала. Ул безнең холкыбызны формалаштыручы скульптор. Шулай ук икътисадчы һәм хуҗабикә: әни өй бюджетын планлаштыра, өйдә уңайлык тудыра, һәр көнне тәмле ризыклар пешерә. Ул гаиләнең матди һәм рухи таянычы. Әни тагын бик күп һөнәрләргә ия . Мәсәлән психолог һәм табиб: без авырганда, ул төн йокыларын калдырып, безнең янда утыра, дарулар бирә. Күңелебез төшкәндә, ул безне тыңлый, юата һәм тормышка яңадан өмет белән карарга өйрәтә. Аның җылы кочагы һәр кайгыны басарга сәләтле. Мин әниемнең никадәр күп көч куйганын үз күзләрем белән күреп үстем. Балачагымда мин еш кына: "Әни нигә бер дә арымый икән?" — дип уйлый идем. Хәзер, үзем зурайгач, аңлыйм: ул арыган, әмма аның мәхәббәте арыганлыкны җиңгән. Кечкенә булганда мин бик авыр хәлгә төшкән идем. Мин бик оялдым һәм бу турыда беркемгә дә әйтәсем килмәде. Әмма әни, берни сорамыйча да, минем кайгылы икәнемне аңлады. Ул минем белән сөйләште, хәлемә керде һәм мине сүкмәде, ә киресенчә, ничек дөрес эшләргә кирәклеген аңлатты. Аның бу сабырлыгы һәм хискә байлыгы мине тормыштагы иң зур авырлыкларны җиңәргә өйрәтте.Мин әниемә чиксез рәхмәтле аның чыдамлыгы өчен. Ул минем бөтен киреләнүемне, хаталарымны һәм бәхәсләремне кичерде. Ул мине һәрвакыт иң яхшы яктан булырга, хыялларга омтылырга өйрәтте. Аның мәхәббәте — ул даими, шартсыз һәм бөтен нәрсәне кабул итүче мәхәббәт. Ул үзе турында кайгыртуны икенче планга калдырып, беренче урынга һәрвакыт балаларының ихтыяҗларын һәм бәхетен куя. Әни булу һөнәре — ул җәмгыятьтәге иң мөһим һәм иң җаваплы эш. Бу хезмәт өчен медальләр яки премияләр бирелмәсә дә, аның нәтиҗәләре безнең киләчәк тормышыбызда, безнең бәхетебездә чагыла. Дөньядагы һәр уңышлы кешенең артында үз баласы өчен бөтен җанын биргән әни тора.

Әнием белән минем уртак хәтерләрем бик күп . Аның белән үткәргән һәр минутны кадерлим. Ял көннәрендә бергәләп пешерелгән алма бәлешенең исе, җәен урманга җиләккә баруыбыз, кышкы кичләрдә бергә утырып әңгәмә коруыбыз – болар барысы да минем күңелемдә якты истәлекләр булып саклана. Ул минем дусларымны да ярата, аларның проблемаларын да үземнеке кебек якын кабул итә.

Минем калган балаларга һәм яшүсмерләргә киңәшләрем: кадерләгез һәм хөрмәт итегез әниләрегезне. Аларның хезмәтен гади кабул итмәгез. Ул сезнең өчен күп нәрсә эшли. Аның фикерен тыңлагыз һәм аны һәрвакыт хөрмәт итегез.Әниләрегезгә карата ярдәмчел булыгыз: өйдәге эшләрне бүлешегез. Аның янына килеп: "Әни, мин сиңа ничек булыша алам?" — дип сорагыз. Бу аның өчен иң зур ял булыр.Без әниләребезгә мең рәхмәтле , шуның өчен ешрак рәхмәт әйтегез: "Рәхмәт сиңа, Әни," дигән гади генә сүз аңа көч өстиячәк. Аны кочаклагыз, яратуыгызны белдерегез.

Мин әниемне бик нык яратам. Ул минем өчен бары тик әни генә түгел, ул — минем иң яхшы дустым, остазым һәм каһарманым. Мин аңа миңа гомер бүләк иткәне, тәрбия биргәне, һәрвакыт ярдәм кулы сузганы өчен чиксез рәхмәтлемен.Әни — безнең тормышыбыздагы иң зур бүләк. Әйдәгез, бу бөек "һөнәр" ияләрен — безнең кадерле әниләребезне — һәрвакыт яратыйк, хөрмәт итик һәм кадерлик., чөнки алар безнең дөньябызны җылылык һәм мәгънә белән тутыручы иң зур көч.

**10 нчы сыйныф укучысы Ганиева Зөһрә**

## Песнәкләр көне



12 нче ноябрь – Песнәкләр көне. Шул уңайдан безнең мәктәптә зур чара булып узды. Башлангыч сыйныф укучылары белән очрашуга Ашыт заказнигы хезмәткәрләре килде. Алар безгә песнәкләр турында сөйләделәр, викторина үткәрделәр. Песнәкләрнең сурәтен дә ясадык әле. Соңыннан урамга чыгып, кошчыкларыбызга дип ясаган җимлекләребезне элеп кердек. Песнәкләр генә түгел, башка кошлар да сыйлансын дып җим салдык. Чөнки кошларга салкында ашарга табуы авыр. Сез дә кошларга җим салыгыз. Тик кошларга ипи һәм тозлы ризыклар бирергә ярамый икән. Канатлы дусларыбыз турында онытмыйк.

**1 нче сыйныф укучылары.**


## Гәҗитне басмага әзерләделәр

**Баш мөхәррир: Сөнгатова Г.З.**
**8 нче сыйныф укучысы :Шакирова Камилә.**
**6 нчы сыйныф укучысы: Галявиева Алия.**
**10 нчы сыйныф укучысы:Гатауллина Илүзә.**